**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГОУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР**
**04.09.2019**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№1483**

**Дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив документларын кулланучыга муниципаль архивның уку залында эшләү өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 ел, 27 нче июль, 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 ел, 22 нче октябрь, 2269 номерлы карары белән расланган дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив документларын кулланучыга муниципаль архивның уку залында эшләү өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән соратуның, дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуның теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 2010 ел, 27 нче июль, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында каралмаган өстәмә документлар һәм мәгълүматлар яисә эшчәнлекне тормышка ашыруны таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итүне кире кагу;

5) федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка

төр норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актларында кире кагу өчен җирлек булмаган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 2010 ел, 27 нче июль, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә билгеле дәүләт хезмәте күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

6) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә күздә тотылган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә документларда алар җибәргән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту, яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган очракта. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә билгеле дәүләт хезмәте күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын һәм тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында моның өчен нигез булмаса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә билгеле дәүләт хезмәте күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гариза бирүчедән беренче тапкыр документларны кабул иткәндә кире каккан вакытта булмаган һәм (яки) күрсәтелмәгән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматларны таләп итү, яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пунктында каралган очраклардан кала дәүләт хезмәте күрсәтү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять

белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә билгеле дәүләт хезмәте күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru/ буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Сабирҗанов Р.Р.ка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин